*Беркем аны югалтмаган,*
*Ләкин һаман табалар.*
*Бигрәкләр дә кызыксына*
*Аның белән балалар.*

*(Табышмак)*



## ТАБИГАТЬ КҮРЕНЕШЛӘРЕ

1

Ләйсән исемле дә була,
Кояшлы да була ул.
Шәһәргә әллә ни түгел,
Аны ярата авыл.

2

Җәен ансыз күк күкрәми,
Яңгыр да сирәк ява.
Аннан соң көн матурлана,
Чистарып китә һава.



3

Ява ул яңгыр булып,
Ява ул карлар булып.
Йөзә бөтен күк тулып,
Исеме аның ... .

4

Канатлары юк — оча,
Ләкин кунар җир тапмый.
Үзе көчле, гайрәтле,
Хәтта кояшны каплый.

5

Сары, кызыл, көрән төстә.
Коела, оча, явалар.
Салкыннарда туңмас өчен,
Кар астында калалар.

6

Чулпан да ул, Зөһрә дә,
Венера да кайчакта.
Матур итеп балкып тора,
Кояш уянган чакта.

7

Көн озая, төн кыскара,
Ел кая таба бара?

8

Ярты икмәк, туп, урак —
Торган җире бик ерак.

9

Күреп була — тоттырмый,
Чөнки бер дә тик тормый.
Тизлеге искитәрлек —
Күзне ачып йомганчы
Җирдән айга җитәрлек.

10

Яшел дә була, кызыл да,
Хәтта була сары да.
Җәен — агачта, ә көзен
Җиргә төшә бары да.

11

Сызгыра да үкерә ул,
Ыжгыра да туздыра.
Беркем дә туктата алмый,
Бөтенесен уздыра.





12

Күренмәсә дә күзгә,
Килә ул кайчак безгә.
Керә дә бакчабызга,
Әйләнә бер явызга.
Суга ул кавыннарны,
Помидор, кыярларны.
Тормый алай озаклап,
Эт белән булмый саклап.

13

Яңгырлы да карлы,
Ә каеннар — сулы.
Бөреләр туп-тулы —
Елның кай фасылы?

14

«Яшен» диеп тә атыйлар,
Ләкин ул уйный гына.
Ялык та йолык иткәли,
Яңгырын коймый гына.

15

Күк тоташкан таулар белән,
Урманнар, кырлар белән.
Арагызда бармы берәү
Шуның исемен белгән?

16

Ялык-йолык итә ул.
Болыт белән килә дә
Болыт белән китә ул.

17

Башларын аска идерә,
Кайчакларда сындыра.
Төтеннәрне, болытларны
Үзенә буйсындыра.

18

Этә, өрә, сызгыра
Һәм тузаннар туздыра.

19

Ишектән һич кергәне юк,
Тәрәзәдән керә ул.
Укырга да комачаулый
Менә шуңа күрә ул.

20

Түбәсе, тәрәзәсе юк,
Сукмаклары — таш кына.
Анда бары ял итәләр,
Күңел шунда ашкына.

